## ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Үрәзмәт авыл җирлеге Үрәзмәт торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“21” ноябрь 2023 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Үрәзмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000(бер мең) сум күләмендә, 1 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 500(биш йөз) сум күләмендә, Луганск һәм Донеск халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә» билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

-Бөек Ватан сугышы һәйкәлен ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү;

-Урам яктырткычларын тоту, яктылык диодлы яктырткычлар сатып алу;

- Ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту: хуҗалык урынын ремонтлау, каты көнкүреш калдыклары өчен түләү, агачларны кисү, үләнне чабу;

- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру;

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге: юлларны ремонтлау, юлларны җәй һәм кыш айларында карап тору, юл буендагы территориядәге үләннәрне чабу;

- Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру һәм тирә-юньне төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 163 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 84 бу 52% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 84 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 0 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлегенең Бүләк торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Үрәзмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә, 1 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә, “Луганск һәм Донеск халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә” һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

-Бөек Ватан сугышы һәйкәлен ремонтлау һәм аның янәшәсендәге территорияне төзекләндерү;

-Урам яктырткычларын тоту, яктылык диодлы яктырткычлар сатып алу;

- Ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту: хуҗалык урынын ремонтлау, каты көнкүреш калдыклары өчен түләү, агачларны кисү, үләнне чабу;

- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру;

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге: юлларны ремонтлау, юлларны җәй һәм кыш айларында карап тору, юл буендагы территориядәге үләннәрне чабу;

- Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру һәм тирә-юньне төзекләндерү;

5. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Үрәзмәт авыл җирлеге башлыгы Ә.Г.Закирҗанов